…ЯЛТ ИТТЕР КҮҢЕЛЕҢНЕ СЫЗЫП АК НУР БЕЛӘН!

# Караш

1999 нчы елның 19 нчы маеннан чыга.
№ 6 2015. МАРТ
«НӘШРИЯТ ЭШЕ» түгәрәге

## БУ НИНДИ ТАВЫШ ДИСӘМ – ЯЗ ИШЕК ШАКЫЙ ИКӘН!

Көннәр аяз, күктән алсу
Нур сибеп, кояш көлә.
Җиргә тама көмеш тамчы –
Сагынып көткән яз килә.
(Мөнир Мазунов)

Кышның салкыннарыннан соң мин язны сагынып көтеп алам. Яз – табигатьнең кышкы йокыдан уяну вакыты. Бүген язның беренче генә көне. Аның әле кыштан әллә ни аермасы юк. Салкын. Бураннар да уйный. Ләкин мин боларны язның кыш белән тартышуы дип уйлыйм. Кояш барыбер үзенекен итә, җылыта. Түбәләргә боз сөңгеләре дә элеп куя. Кояш җылырак карау белән, боз сөңгеләреннән туктаусыз тамчылар сикерә башлый. Алар кояш нурларында энҗе кебек ялтырыйлар. Түбә калайларыннан пар күтәрелә. Чыпчыклар һәм песнәкләр дә күңеллерәк чыркылдаша.

Көннәр дә озыная бара. Яз кояшы елмаеп карау белән, бөтен табигать кышкы йокысыннан уяна башлый. Кояш балкый, ул өй түбәләрендәге карларны эретә. Карлар эри башлагач, җылы яклардан кошлар да кайта башлар. Язгы җылы җил агачтагы яшь бөреләрне уятыр. Тиздән алар хуш исле яшел яфраклар ярырлар. Кояш эссе нурларын көннән-көн күбрәк сибәр. Җирдән җырлый-җырлый гөрләвекләр челтерәп агар. Бозлар кузгалыр. Кырларда беренче умырзая баш калкытыр. Кешеләр язгы эшләргә керешерләр. Язның да эше күп: иңе-буе күренмәгән кырларны кардан әрчисе, ямь-яшел ужым басуларын ачасы бар. Кырларда тиздән тракторлар гөрләр – язгы кыр эшләре башланыр. Язның әле дымлы җирне үләннәр һәм аллы-гөлле чәчәкләр белән бизисе бар.
Ә бүген әле март башы гына. Төннәрен салкын булса да, көндезен инде кояш балкый. Туган җиребезгә яз килә, яз исе аңкый. Яз – матур, шатлыкларга бай, күңелле вакыт. Түрдән уз, яз!




*Сөекле, әбиләр, әниләр, апалар, сеңелләр! Сезне 8 нче март – Халыкара хатын-кызлар көне белән котлыйбыз. Исән-сау булып, имин тормышта җан тынычлыгы белән матур гомер кичерергә язсын!*

БУ АЙДА... “Йолдызлык” фестивале уза. Әлеге фестивальдә безнең укучыларда үз талантларын күрсәттеләр.
БУ АЙДА... ниһаять “Ягез әле, КЫЗЛАР” бәйгесе булды. Аны кызыклы һәм онытылмаслык итеп үткәрү үзебездән тора шул. Кызлар бәйгегә бик тырышып әзерләнгәннәр, молодцы, кызлар! БУ АЙДА... уку елының өченче чиреге тәмамлана. Ниһаять, каникул!!!

# БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ 70 ЕЛЛЫГЫН КАРШЫЛАП...

## Онытырга хакыбыз юк!

Еллар уза, дөньяга яңа буыннар килә. Ватан сугышы беткәнгә дә инде шактый вакыт узып бара. Әмма сугыш хатирәләре, дошманга күкрәк киереп каршы торган, изге җиребезне саклап калган, аның иминлеге өчен гомерләрен дә кызганмаган каһарманнар һичкайчан онытылмас. Җиңү бәйрәмнәре тагын шаулап узар. Ләкин кешеләр йөрәгендә сугыш калдырган яралар һаман да сыкрый шул әле. Сугыш афәтен башыннан кичергән кешеләр кабат сугыш булуын һичкайчан теләмәсләр.

Бөек Ватан сугышына безнең районнан 19852, безнең Лашман авылыннан гына да 335 кеше киткән. Яулыклары белән авыз читләрен каплап, тавышсыз гына елап, хәсрәтен эчләренә йотучы аналар һәм апалар газиз ирләрен, сөйгәннәрен соңгы тапкыр күрүен аңламаган әле ул чакта. Сугыш җиле кагылмаган берәр йорт калдымы икән? Сугыш барганда, һәр йортны, һәр гаиләне кайгы, үлем сагалап йөргәндә,соңгы өметләрне өзеп, өйләргә үлем язулары килгәндә, ул еллар һич узып китмәслек озын булып тоелгандыр.

Берәүне дә аямаган сугыш,
Баштан сыйпамаган яратып.
Аналарны яшьли тол калдырган,
Нәселләрне кискән корытып.

Тулы бер гаиләләрне йота ул. Авылыбыздан Абзаловлар гаиләсе - 5 ир туган һәм этиләре... Авылыбызның уртасында сугышта һәлак булучылар истәлегенә куелган мемориаль тактадагы исемлек башында тора алар.

Абзалов Габдерахим Абзал улы
Абзалов Вәгыйз Абзал улы
Абзалов Габдулла Абзал улы
Абзалов Әгъзам Абзал улы
Абзалов Бари Абзал улы

Тулы бер гаилә... Кулларыма “Хәтер” китабын алам. Мәктәбебез музеендагы материалларны барлыйм...

Чирмешән районы (ул чакта әле ул Беренче Май районы) Лашман авылында яшәп ятучы Шәмсениса һәм Абзал бабай гаиләсендә бөркет кебек уллар үсә. Аларның иң олы уллары Габдулла сугыш чыкканда үзе дә биш бала атасы була. 36 яшендәге типсә тимер өзәрлек ир сугышның беренче көннәрендә үк сугышка китә. Ил солдаты 1942 нче елның 9 нчы сентябрендә Воронеж өлкәсенең Лиски районы Сторожевое авылында мәңгелеккә башын сала... Биш баласы ятим, хатыны тол кала.

Икенче бөркет – Бариның сугышчан юлы озак вакытлар билгесез була. “Хәтер” китабында да аның үлем датасы һәм урыны күрсәтелмәгән. Бары тик басманың өстәмә исемлегендә исә Абзалов Бари Абзал улының 1942 нче елның 14 нче апрелендә Финляндиядә әсирлектә үлүе хакында язылган. Мәрхүмнең Сәмига һәм Сания исемле кызлары һәм ул фронтка киткәч туган улы Мидхәт ятим кала. Ятимлек ачысына өстәп, озак еллар әле алар хәбәрсез югалучыларга тагылган “хыянәтче” сүзе өчен дә әрниләр...

Абзал бабайның өченче уллары Габдерәхимне сугышка егерме сигез яшьтә алалар. Яңа гына өйләнгән яшь ир гаилә бәхетен дә татып өлгерми. Яңа туган баласын күкрәгенә сөеп кыса да, ил азатлыгы өчен көрәшкә китә...

Дүртенче туган Вәгыйз егерме дүрт яшьтә китә. Аның һәм абыйсы Габдерәхимнең кайчан, ничек һәлак булулары һәм кайда җирләнүләре хакында бернинди мәгълүмат юк. Алар хәбәрсез югалган... Ана йөрәгенә күпме хәсрәт!

Шәмсениса әбинең бишенче бөркете – Әгъзам сугыш тәмамланырга өч ай калгач кына, Балтыйк буенда барган дәһшәтле бәрелешләрдә шәһит китә һәм Калининград өлкәсенең Фрауендорф авылында җирләнә.

Бер ананың биш улы әнә шулай немец илбасарларыннан Ватаныбызны саклап калу өчен бер йодрык булып берләшеп, изге сугышка киткән, бишесе биш фронтта көрәшкән, Ватан азатлыгы өчен яу кырында мәңгелеккә башын салган...

Халык хәтере мәңгелек. Сугыш тәмамлангач, Абзаловлар орден-медальләр тагып кендек каннары тамган туган туфракларына аяк баса алмасалар да, алар безнең йөрәгебездә. Габдулла, Бари. Габдерәхим солдатларның нәселен дәвам итеп тугыз бала кала. Сугыш арты еллары ничек кенә авыр булмасын, алар исән-имин үсеп җитәләр, гаиләләр коралар. Еллар уза, буыннар алмаша. Илебез Бөек Җиңүнең 70 еллыгын тантана итәргә җыенган көннәрдә Шәмсениса әби белән Абзал картның оныкларының да оныклары бүген горурлык хисе белән иркен Ватаныбызда яшиләр. Араларында төрле һөнәр ияләре – табиб, укытучы, хисапчы, нефтьче, эшмәкәрләр...

Илебез азатлыгы өчен көрәштә гомерләре өзелгән биш бертуган – Габдулла, Бари, Габдерәхим, Вәгыйз, Әгъзам Абзаловлар истәлеген кадерләп саклыйбыз. Бу солдатларның исемнәре, батырлыгы якты маяк булып, буыннардан-буыннарга күчәр дип ышанам.

Бүгенге тыныч тормышыбыз, аяз күгебез, мул табыныбыз өчен башын салган авылдашларыбыз рухы тыныч булсын. Без аларга рәхмәтле.



# УКЫРГА КАЯ БАРЫРГА?

**Казан (Идел буе) федераль университеты — Казан шәһәренең югары уку йорты. Россиянең иң борынгы университетларыннан берсе. 1925 елдан 2009 елга кадәр В. И. Ленинның исемен йөртә. 2009 елның 21 октябрендә Россия Президенты фәрманы буенча Казан дәүләт университеты нигезендә — Казан (Идел буе) федераль университеты оештырыла.**

220 ЕЛ ЭЛЕК 1804 елда император Александр I Казан университетын ачу турындагы фәрманга кул куя. Ул Россия күләмендә өченче универ- ситет (Россиянең Мәскәү һәм Тарту шәһәрләрендә генә була) санала. Казан тиз арада иң зур фәнни һәм мәдәни үзәккә әверелә. Университет Беренче шәһәр гимназиясе нигезендә оештырыла. Гимназистларга студент исеме бирелә. Казан университеты тиздән тулы бер комплекс тәшкил итә башлый. Химия лабораториясе, анатомия театры, китапханә төзелә. Шулай ук университет ишегалдында астрономия лабораториясе һәм студентлар клиникасы ачыла. ХӘЗЕР Бүгенгесе көндә КФУ күп юнәлешләр буенча белем бирә. Университет эчендәге институт һәм факультетлар:

- Фундаменталь медицина һәм биология факультеты
- Экология һәм табигатьтән файдалану институты
- Геология һәм нефть-газ технологияләре институты
- Н. И. Лобачевский ис. математика һәм механика институты Физика институты
- А. М. Бутлеров ис. химия факультеты
- Юридик факультет
- Идарә итү һәм территориаль үсеш институты
- Мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системалар югары мәктәбе
- Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты
- Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты
- Массакүләм багланышлар һәм иҗтимагый фәннәр институты
- Икътисад һәм финанслар институты
- Халыкара мөнәсәбәтләр, тарих, һәм Шәрекъне өйрәнү институты
- Педагогика һәм өйрәнү институты
- Тел институты

ФИЛИАЛЛАР. Университетның филиаллары Яшел Үзән һәм Чаллы шәһәрләрендә эшли, ә Алабугада исә КФУның аерым институты урнашкан.

ИСТӘЛЕКЛЕ УРЫННАР. Химия факультеты бинасы каршындагы бакчада озак еллар университетта эшләгән Н. И. Лобачевскийның һәйкәл-бюсты тора. Ә Студентларның яраткан ял итү урыны булган "таба" (түгәрәк формада булганга шулай атала) төп бина каршында урнашкан. Киләчәктә, бәлки, бу урын синең дә яраткан почмагың булыр, кем белә бит.




ШӘХЕСЛӘР 200 елдан артык тарихы булган университет бусагаларын кемнәр генә атлап кермәгән?! Студентлар бүген Сергей Аксаков, Лев Толстой, Владимир Ленин эзләренә басып йөри. ЧИТ ИЛЛӘР Чит илләргә сәяхәт итәргә яратсаң, КФУ анысын да җайлаштырган. Студентлар алышу программасы белән КФУ студентлары АКШ, Япония, Финляндия, Швейцария, КНР, Италия, Мексика, Франция, Көньяк Корея кебек илләргә бара алалар. МӘГЪЛҮМАТ Казан федераль университеты турында күбрәк мәгълүмат аласың килсә, интернет челтәрендәге сайтка рәхим ит:

http://kpfu.ru Уку йортының русча һәм татарча газеталары белән безнең редакция бүлмәсендә танышырга мөмкин. КФУ ел саен үзенең төбәкара олимпиадаларын уздыра. Анда теркәлү өчен, abiturient.kpfu.ru адресы буенча махсус сайтка керегез.

## КАН ЭЧҮЧЕ “ДУСЛАРЫБЫЗ” - ВАМПИРЛАР

Кешегә вампирлар дип сөйли башласаң, ул көләргә тотыныр. Кинода гына ич алар, син хыяллангансың, дип тә өстәп куярга мөмкин. Ләкин бу очракта без бик тә ялгышабыз Бөек Тукай әйткәнчә: “Күктә ни булмас дисең, очсыз-кырыйсыз күк бит ул”. Әле җир йөзендә аңлатып булмаган , галимнәр тарафыннан ачыкланмаган бихисап күп әйберләр барлыгына киная бу фраза. Тарих битләренә күз салсак, вампирларның килеп чыгуы Польшадан башлана. Анда алар көтүләре белән яшәгәннәр. Кешеләрнең каннарын эчеп туенганнар. Һәм элеккеге заманда кешеләр вампирларның чынбарлыкта яшәгәнен бик яхшы исбатлаганнар. Аларның сөйләве буенча, теләсә кем вампирга әйләнә алган. Ләкин моның өчен башта бер кешене үтереп, аның канын соңгы тамчысына кадәр эчеп бетерергә кирәк булган. Үлгән кеше шулай ук вампирга әйләнә алган. Моның өчен, аны күмгәннән соң кабере өстеннән кап-кара песи сикереп чыгарга тиеш булган. Үлгән кешенең туганнары каберлекне саклап, янына песиләрне җибәрмәскә тырышканнар. Португалия якларында иң зур һәм көчле вампир булып Брукса исемлесе саналган. Әле бүгенге көннәрдә дә португаллар, аның барлыгына ышанып һәм аннан куркып яшиләр икән. Якты вакытта ул гап-гади хатын-кыз рәвешендә булса да, карангы төшкәч, ул, кошка әйләнеп, яшь балаларның каннарын эчеп йөргән икән. Билгеле даирәләрдә танылган галим Стефан Каплан 1972 нче елда Нью-Йоркта вампирларны эзләү һәм исбатлау өчен зур тәҗрибә үзәге ачкан. Ул бик күп эзләнүләрдән соң 10 вампирны тапкан. Аларның барысы да гади кеше кыяфәтендә булганнар. Тәҗрибәләреннән соң, Стефан Каплан мондый фикерләргә килгән:



- вампирлар безнең гасырда да яшиләр;
- алар кояштан куркалар, шунлыктан кояштан саклану күзлеге кияләр, ә тәннәренә крем сөртәләр; - тешләре дә, тырнаклары да аларның гади кешеләрнеке кебек;
- алар кошка, җәнлекләргә һәм башка әйберләргә әйләнә белмиләр;
- алар кешенең канын эчәләр, ләкин аларга үзләренең кан эчү теләген бетерер өчен атнага - өч тапкыр 50 миллиграмм кан җитә;
- әгәр дә алар кан эчәргә кеше тапмыйлар икән, урманга барып хайваннарның каннарын эчәләр икән. Ләкин аларга бу хәлләр бер дә ошамый.

Менә шундый мәгълүмат. Барыбызга да мәгълүм “Сумерки” фильмында вампирлар арасында да төрле катлау һәм типлар булуын белгән идек. Димәк, бу өлешчә дөреслеккә якын.

## Мәктәпләрдә, мәктәпләрдә, мәктәпләрдә...



Мәктәп – безнең икенче йортыбыз, анда безнең дусларыбыз, яраткан укытучыларыбыз. Кемнәрдер мәктәпкә укырга дип, кемнәрдер дуслары белән күрешергә дип йөрсә, икенчеләре тәмле-тәмле ризыклар, пирожкилар өчен йөри кебек миңа. Инде мәктәп темасына кереп киткәч, бераз мәктәп турындагы кайбер мәгълүматлар белән дә танышып китик. Безнең өчен 1 сентябрь уку башланган көн булып саналса да, кайбер илләрдә ул бөтенләй башка дата. Мәсәлән, Испаниядә мәктәп бусагалары кырлардан уңыш җыелып беткәч кенә ачыла, ә Дания укучылары август урталарыннан ук укый башлыйлар икән. Ә менә Япониядә укуны бик күңелле итеп кабул итәләр һәм уку да аларда 1 апрельдә башлана. Иң борынгы уку йорты – Фес шәһәрендә урнашкан Карауин мөселман университеты икән. Бу университет б.э.к. 859 елда ачылган булган. Иң күп укучыны үзенә туплаган мәктәп Һиндстанда. Анда 28000 укучы белем ала. Иң кыйммәтле мәктәп - “Халыкара яшь туташлар һәм әфән-деләр мәктәбе”. Бу мәктәптә уку аена 77,5 мең доллар, ягъни 2 500 000 сум тирәсе тора. Чыгарылыш укучыларының иң зур очрашуы Алманиядә була. Анда 2 500 кеше килә. Америка яшүсмере уку өчен якынча 12 000 сәгать сарыф итсә, телевизор карауга аның 14 000 тирәсе сәгать әрәм ителә. Безнең илдә иң югары билге “5”ле, ә иң түбәне “1” ле саналса, Чехиядә киресенчә икән. Аларда “1”ле алу бик сөенечле хәл. Ә инде ашханәгә килсәк, статистика буенча малайлар ашханә өчен акчаны кызларга караганда 3 тапкыр күбрәк тоталар икән. Безнең мәктәптә дә малайларның пирожки өчен үлеп торулары моңа бер дәлилдер.

“Караш” газетасының әлеге саны өчен җаваплы: Газимзянова Р. Ф.
Хәбәрләшү өчен телефон: 9270444015